СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан. 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар                                   Решение

№ 3-45                                   14 нче октябрь 2019 ел

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында**

2019 нчы елның 26 июлендәге 226-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә нотариат турындагы законнар нигезенә һәм "Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 16_1 статьясына үзгәрешләр кертү турында"гы Федераль законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 37 статьясында каралган нотариаль гамәлләр кылу хокукына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегенең түбәндәге вазыйфаи затлары ия:

Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе һәм (яисә) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтле вәкиле.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты секретарен тиешле авыл җирлегендә нотариаль гамәлләр башкаруга вәкаләтле вазыйфаи зат итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге җирле үзидарәсенең әлеге карарның 1, 2 пунктларында күрсәтелгән вазыйфаи затлары Урта Кирмән авыл җирлегендә, торак пунктта

яшәү урыны яки тору урыны буенча теркәлгән затлар өчен түбәндәге нотариаль гамәлләр кылырга хокуклы:

1) кучемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен расларга;

2) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән Мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрергә;

3) документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең тугрылыгын раслау;

4) документларда имзаның чынлыгын дәлилләү;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында белешмәләрне таныклыйлар;

6) гражданның исән булу фактын таныклыйлар;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалидның үз имзасының, үз кулы белән куелган имзасын факсималь күрсәтеп, тәңгәллеген расларга;

8) билгеләнгән урында гражданның урнашу фактын таныклыйлар;

9) фотода сурәтләнгән зат белән гражданинның тәңгәллеген таныклыйлар;

10) документлар тапшыру вакытын таныклыйлар;

11) электрон документның кәгазьдә урнаштырылган документ белән тәңгәллеген раслыйлар;

12) кәгазьдәге документның электрон документка тәңгәллеген таныклыйлар.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2008 елның 29 гыйнварында кабул ителгән 4-20 санлы «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында»гы, 2008 елның 09 декабрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2008 елның 29 гыйнварында кабул ителгән 4-20 санлы «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 2-27 санлы карарын, 2011 нчы елның 29 мартында кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2008 елның 09 декабрендә кабул ителгән 2-27 санлы «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 8-4 санлы карарларын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (<url>) pravo.tatarstan.ru). урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Хасанов Булат Фаязовичка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /Б.Ф.Хасанов/